ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422350, штп. Апас, Советская урамы,

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

№ 86 от 13.05.2025

«Апас муниципаль районында 2021-2025 елларга яшьләр сәясәтен үстерү " муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында»

Студентлар отрядлары эшчәнлеген оештыру һәм хезмәт тәрбиясе максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18 мартындагы 78 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Апас муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасына (алга таба текст буенча – программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

программа паспортында " программа бурычлары» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 8,9,10 пункт өстәргә:

«8.Студент отрядлары эшчәнлеген үстерү һәм оештыру өчен шартлар тудыру, аларның эшчәнлеген оештыру һәм координацияләү.

9.Студент отрядлары әгъзаларын әзерләү, эшкә урнашуда ярдәм итү (шартнамәләр төзү, отряд командирларын һәм комиссарларын әзерләү һәм квалификациясен күтәрү, хезмәтне саклауны контрольдә тоту мәсьәләләре буенча ярдәм күрсәтү);

10.Яшьләргә хезмәт тәрбиясе бирү, халык арасында мәдәни һәм социаль әһәмиятле эштә студент отрядлары хәрәкәте традицияләрен үстерү һәм аларга ярдәм итү.»;

Программага кушымтадагы таблицага түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

	Студентлар хәрәкәтен үстерү чараларын оештыру	Апас аграр көллиятендә студентлар отрядларын төзү буенча агитация кампаниясен гамәлгә ашыру	ТР Апас муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм яшьләр бүлеге, Апас аграр көллияте	025	Студентларның хезмәт отрядлары хәрәкәтендә катнашучы яшь кешеләрнең өлешен 2,4 кә кадәр арттыру%											,4%	
		Студентлар отрядлары эшчәнлеге өчен норматив база булдыруда ярдәм күрсәтү	ТР Апас муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм яшьләр	025													

			бүлеге, Апас аграр көллияте														
		Студ ентлар отрядлары штабын оештыру һәм аның утырышларын үткәрү	ТР Апас муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм яшьләр бүлеге, Апас аграр көллияте	025													
		Студ ентлар отрядларының эш планнарын эшләүдә ярдәм итү	ТР Апас муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм яшьләр бүлеге, Апас аграр көллияте	025													
		Студ ентлар отрядларын эшкә урнаштыруга ярдәм итү	ТР Апас муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм яшьләр бүлеге, Апас аграр көллияте	025													

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җитәкченең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче **Б. Н. Әхмәтҗанов**